РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЛАННИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАЛАНЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

*423973, Р.Т. Муслюмовский район, с.Баланны, ул.Советская д.80*
Balan.Mus@tatar.ru *тел. (8-85556) 3-68-82*
ИНН 1629003960, КПП 162901001, ОГРН 1061687005192, ОКАТО 92242810000.

---

Баланлы авылы 24 февраль 2021 ел.

**Карар № 6**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге Башкарма комитетының 20.02.2017 елның №5 карары белән расланган «Баланлы авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. « Баланлы авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге Башкарма комитетының 20.02.2017 елның №5 карары белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**Түбәндәге эчтәлектәге пункт белән тулыландырырга:**

«2.6.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документларны үз карамагына алган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма:

1) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык мәгълүмат).

2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына Россия Федерациясе законнары нигезендә түләү вакыты җиткән салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри бурыч булмау турында белешмә (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш).»;

Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге регламентның 2.6 пункты белән билгеләнгән.»;

**2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:**

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.»;

**3.3 пунктының 2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:**

«салымнар, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурыч булу (булмау) турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru сайты буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баланлы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И.Исламова